предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, шәһәр һәм район оешмаларында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыруны.

1.1.4. Балаларның ял һәм сәламәтләндерү учреждениеләрендә балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, санитар-эпидемиологик, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгы, судагы куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү һәм үткәрүне.

1.1.5. Һәр смена башланыр алдыннан ял итү оешмаларын, санитар кагыйдәләргә, суда кеше тормышын саклау кагыйдәләренә, хезмәткәрләрнең хезмәт шартларына һәм торышына, ял итүчеләрнең куркынычсызлыгына, мунча-кер юу комплексларын карап тотуга, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы жайланмаларының, янгын турында кешеләргә хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, беренчел янгын сүндерү чараларының булуына һәм төзеклегенә, шулай ук персоналның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүләренә тикшерү максатыннан комплекслы тикшерү оештыруны.

1.1.6. Санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашырырга вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүне раслаучы документ булганда, шулай ук янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләр тулы күләмдә үтәлгәндә генә балаларның ял һәм сәламәтләндерү оешмаларын ачуны.

1.1.7. Санитария кагыйдәләрен үтәү һәм билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән лаборатор-инструменталь тикшеренүләр уздыруга шартнамәләр төзү юлы белән санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар башкаруны.

1.1.8. Җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чоры дәвамында урман-техник эшләр чаралары (агачларның, куакларның аскы һәм коры ботакларын кисү, кирәкмәгән яшь үсентеләрне кисү, үлән чабу, балаларның ял итү һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләреннән коры ауган агач һәм чүп-чарны чыгару), шулай ук лагерь тирәли 500 метр радиуста дератизация һәм талпанга каршы эшкәртүләр үткәрүне.

1.1.9. Барлык корылмаларны, шул исәптән файдаланылмый торган, ачык территорияләрне, 500 метр радиуста балалар ялы оешмалары тирәсендәге барьерны һәм лагерьлар ачылганчы 10-14 көн алдан һәм аларны консервацияләү алдыннан, шулай ук сменалар арасында корылмаларны дератизация буенча эшкәртү үткәрүне.

1.1.10. Балалар ял лагерьларын ачарга 14 көн кала, лагерь территориясен һәм аннан 50 метр зонада, шулай ук энтомологик күрсәткечләр булганда, сменалар арасында талпаннарга каршы эшкәртү үткәрүне.

1.1.11. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331, 351.1 маддәләре таләпләре нигезендә ял оештыруда эшкә урнашкан затларга, хөкем ителү һәм (яисә) җинаять эзәрлекләве факты булу яисә билгеле бер җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвен туктату предметына алдан тикшерүләр үткәрүне оештыруны.

1.2. Оештырырга:

1.2.1. Талпан энцефалитын, боррелиозны һәм бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатларында, лагерьлар ачылыр алдыннан, акарицид эшкәртүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тоту (кулланыла торган препаратка карап, эшкәрткәннән соң 3-5 көндә), шулай ук билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән

Шәһәр яны лагерьларында профильле сменалар оештыру

Табл. №6

| Шәһәр яны лагеренең исеме | Үткәрү территориясе | Лагерьны балансta тотучының исеме | Кеше саны * | Көннәр саны * | Юлламаның нормативе бәясе | Бюджеттан субсидияләр* | Ата-аналар взносы* | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль задание нигезендә | | | | | | | | |
| «Йолдызлык» БЯЛ» МБУ | Лагерь базасы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | 100 | 18 | 14773,32 | 12557,34 | 2215,98 | - |
| «Йолдызлык» БЯЛ» МБУ | Лагерь базасы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | 15 | 7 | 5745,18 | 4883,41 | 861,77 | - |

Җәйге ялны оештыруны тәэмин итү чыгымнары

Табл. №7

| Муниципаль казна учреждениесенең исеме | Үткәрү территориясе | Балансta тотучының исеме | Бюджеттан субсидияләр * |
|---|---|---|---|
| "ЗМР Башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ | Мәктәп яны лагерьлары | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | 8,200 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Тормыш эшчәнлеген яхшырту һәм балаларның имин булмавы проблемаларын хәл итү | Балалар көндез йөри торган хезмәт һәм ял лагерьларын ачу | “ЗМР Башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ | 01 июнь 2020 - 29 июнь 2020 | Балалар саны (квота буенча) | 500 | 500 | 3090,24 (Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм ата-аналар акчалары) |
| | Балалар һәм яшьләр ижтимагый оешмаларына ярдәм итү; сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, ижади конкурсларда жиңүчеләрне ачыклау, аларга ярдәм итү системасын формалаштыру | Шәһәр яны лагерьларында профильле сменалар ачу | “ЗМР Башкарма комитеты яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 10 август 2020 – 27 август 2020 | Балалар саны (квота буенча) | 115 | 115 | 17440,75 (Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм ата-аналар акчалары) |
| | | Палаткалы лагерьларда профильле сменалар оештыру | “ЗМР Башкарма комитеты яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | июль | Балалар саны (квота буенча) | 30 | 30 | 5974,43 (Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм ата-аналар акчалары) |
| | Каникуллар чорында балаларны, яшьләрне ял иттерү, сәламәтлекләрен ныгыту | Муниципаль һәм дәүләт оешмалары, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар (искәрмә: муниципаль һәм дәүләт оешмалары) хезмәткәрләре балалары өчен шәһәр яны лагерьларында сменалар оештыру | “ЗМР Башкарма комитеты яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 01 июнь 2020 – 27 август 2020 | Балалар саны (квота буенча) | 315 | 315 | 22246,77 (Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм ата-аналар акчалары) |

